КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 апрель г.Казань № 206

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче, 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.6 пунктында «үткәргәндә» сүзләренә кадәр «яки иҗтимагый фикер алышулар» сүзләрен өстәргә;

4 бүлекнең 4.1.1 пунктында икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проектлаштырганда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары нигезендә эш итәргә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт программаларындагы,

муниципаль программалардагы, Россия Федерациясен, Татарстан Республикасын, муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үстерү стратегияләрендәге тәкъдимнәрне исәпкә алып.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин